# СӘЛӘТЛЕ БАЛАЛАР БЕЛӘН ЭШЛӘГӘНДӘ, УКЫТУЧЫНЫҢ ПРОФЕССИОНАЛЬ КОМПЕТЕНЦИЯЛЕ БУЛУЫНЫҢ ЗАРУРЛЫГЫ

*Хуҗина Рузилә Тәлгать кызы, 12 нче кызлар гимназиясенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

Кызыксындырып укыта белгән кеше генә яңа үрләр яулый.
А. Эйнштейн

Хәзерге үзгәрешләр заманында, күп өлкәләрдә яңалыклар туып торганда, заман укытучысына үз профессиональ дәрәҗәсен үстерү өстендә өзлексез эшләргә туры килә. Бүген шәхес үстерүдә төп фигура булып калуда, педагогка анын тумыштан килгән төпченү, бер нәрсәне беләсе килү кебек сыйфатлары ярдәм итә. Бу искиткеч сыйфат - һәр нәрсәнең асылына төшенергә теләү - куп педагогка хас күренеш. Нәкъ менә шушы сыйфат аларга күп өлкәләрдә компетентлы булырга һәм үз укучыларында компетентлылык формалаштырырга ярдәм итә.

Компетентлы булу өчен проблеманы билгеләү генә җитми эле. Аңа яхшылап төшенергә, чишелү юлларын белергә, берничә ысул белән чишелүен өйрәтергә кирәк. Ә бу проблеманы махсус өйрәнүне, ягъни үз өстендә профессиональ үсеш өстендә эшләүне таләп итә.

Татар теле һәм әдәбияты укытучысы ничек, кайда белемен күтәрү өстендә эшли ала?

Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан 4 - 5 г а бер үткәрелгән квалификация күтәрү курсларында, дип җавап бирсәк, бик үк дөрес булмас, мөгаен. Ләкин укытучы анда үз белемен күтәрү өстендә эшләүнең юнәлешләрен билгели ала. Хезмәттәшләренең активлыгын тою, курслардагы эчкерсез эшлекле шартлар фикер алышу - укытучы өчен зур этәргеч. Курсларда алган, күргән багаж беткәч, чын иҗади эзләнү, төрле чыганакларга мөрәҗәгать итү башлана. Уз өлкәңдә, хезмәтеңдә компетентлы булу теләге уяна.

Компетенция - латин теленнән кергән сүз." Татар теленең аңлатмалы сүзлеге"ндә ул "нинди дә булса өлкә мәсьәлә буенча яхшы хәбәрдарлык, белемлелек" дип бирелә. Ә компетентлы" нинди дә булса өлкә, мәсьәлә буенча яхшы хәбәрдар, тирән белемле, төпле, ышандыргыч авторитетлы"
диелә.( Татар теленең аңлатмалы сүзлеге , К.,1979, 141б.)

Бу терминнар Европа илләрендә һәм Америкада 7 0 нче елларда ук киң кулланыла.

Компетентлылык формалаштыру фәннәрнең тел нигезләрен өйрәтүне генә түгел, ә укучыларның кызыксыну дәрәҗәләреӊ эшчәнлеген, интеллектуаль үсешен күз алдында тота.

Белем бирү һәм тәрбия өлкәсендә компетенцияләрне гомуми һәм махсус, ягъни профессиональгә бүлеп карыйлар. Гомуми компетенцияләргә ия булу шәхеска социаль тормышта үз урынын табарга, дөньяга билгеле бер караш тәбияләргә, гражданлык позициясен ачыкларга булыша.Ә профессиональ компетенция нинди дә булса бер өлкәдә кирәкле белем, күнекмәләргә ия булуны аңлата.

Җәмгыять тормышында кирәклеге ягыннан профессиональ компетенциянең 5 төрен күрсәтәләр: сәяси һәм социаль, культура ара ( межкультурная), коммуникатив (аралашу), информацион - технологик , профессиональ. Санап үтелгән компетенцияләр татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә дә формалашалар.

Сәяси - социаль компетенция - җаваплылыкны үз өстеңә алу, конфликтларны үзара тыныч юл белән чишү, тормышны яхшы якка үзгәртергә тырышу.

Информацион - технологик компетенция - яңа технологияләрнең кеше тормышына тәэсир итүең аларның яхшы һәм тискәре якларын ачыклау, төрле мәгълүмати һәм реклама каналларына аек акыл белән карау дигән сүз.

Профессиональ компетентлылык галимнәр тарафыннан гомерен буе белем алу, укырга омтылу дип билгеләнелә. Бу инде үз белемеңне күтәрү өстендә өзлексез эшләү дигән сүз.

Гимназиябез, мәгариф системасын модернизацияләү шартларында индивидуаль һәм дифференциаль алымнар кулланып,укучы шәхесен үстерү юнәлешендә эшли. Сәләтле балалар һәр мәктәптә дә бар. Белгечләр исбатлавынча, сәләтле балаларның нәрсәгә сәләтле булуы билгеле бер шартларда ачыклана. Сәләтле булу нәселдәнлеккә генә бәйле түгел, монда баланың тирә-ягындагы кыйммәтләр системасы да зур әһәмияткә ия. Билгеле бер шартлар булдырганда, укучыларның күбесендә теге яки бу сәләтне үстерергә мөмкин.

Татарстанда сәләтле балалар белән эшләү системасы булдырылган."Мәгариф" журналыннан алынган мәгълүматларга Караганда (2007 ел, № 2 ), республикабыз фән олимпиадалары нәтиҗәләре буенча, Мәскәүдән кала, икенче урында тора. Бу уңышта безнең дә өлеш бар, чөнки 2006-2007 нче уку елы гимназиябез өчен уңышларга бай булды Шәһәр олимпиадаларында Нәбиуллина Әнисә ( 11 кл.) рус теленнән беренче, Хәкимуллина Ләйсән ( 9 кл. ) рус әдәбиятыннан икенче, Петрова Катя ( 8 кл.) математикадан беренче урыннарны яуладылар. Республика олимпиадалары нәтиҗәләре дә куанычлы: татар теленнән Гәрәева Альмира ( 10 кл. ) беренче, рус әдәбиятыннан Емелина Женя ( 10 кл. ) беренче, Фомина Саша ( 11 кл. ) икенче, җәмгыять белеменнән Фомина Саша дүртенче урыннарга лаек булдылар. Укучыларыбыз теоретик материалларны яхшы үзләштерүләрен һәм белемнәрен практикада куллана белүләрен курсәттеләр.

Теләсә нинди фәнгә мәхәббәт, аны тирәнтен өйрәнергә омтылыш иң элек бу фәннән белем бирүче укытучыдан башлана. Оста укытучы, укучының теге яки өлкәдәге кызыксынуларын күреп, ачып, аны тагын да үстерә ала.

Гимнизиядә укучыларның иҗади сәләтләрен үстерү өлкәсендә дә зур эш башкарыла."Татар кызы" бәйгесендә районда икенче урынны алган кызыбыз .Таишева Ләйсәнгә ( 11 кл. ) Чехиядә үткәрелгән халыкара конкурста беренче дәрәҗәдәге лауреат дипломы тапшырдылар. Мөнәҗәтләр уку остасы, җырчы сандугачыбыз Булатова Алинә ( 10 кл.) Казахстан Республикасындагы төрки халыклар фестиваленнән беренче дәрәҗәдәге лауреат исеме алып кайтты. Бөек шагыйребез Г. Тукайга багышланган шигырь уку бәйгесендә гимназиябез укучысы Герфанова Румия ( 10 кл.) районда беренче , шәһәрдә икенче урыннарга лаек булды. Шул ук бәйгедә 8 кл. кызлары Орынбаева И. һәм вьетнамлы Буй Тхи Хонг

районда икенче урынны булештеләр. ( Татар милләтеннән булмасалар да, кызларыбыз бик тырышып татар телен өйрәнәләр, укылган әсәрләрнең эчтәлеген әдәби телдә сөйлиләр.)

Укучыларыбызның кызыксынулары төрле.Белемнәрнең киләчәктә дә кирәк булуы сәләт үстерәдә төп тимул .Шуңа да алар шәһәрдә үткәрелгән бәйгеләрдә үзләрен сынап карыйлар һәм уңышларга ирешәләр. КДУ да Ш. Мөдәррис исемендәге тәрҗемәчеләр конкурсында Нәбиуллина Әнисә , татарчадан инглизчәгә тәрҗемә итеп , өченче урынны яулады. ТДГПУда ,шәһәр үткәргән "Мин - иң яхшы укытучы" бәйгесендә, Гәрәева Альмира өченче урынга лаек булды.

Сәләтле балаларыбыз академик Җәүдәт Сөләйманов җитәкчелегендәге "Сәләт" лагерында ял да итеп кайттылар.Элеккеге укучыбыз Гатауллина Алсу (хәзерге вакытта КДУ ның икенче курс студенты) "Сәләт"тә "Рухият" бүлеген җитәкли.

Сәләтле балалар белән эшләгәндә, яңа мәгълүмати технологияләргә таянып, аерым эш планы булдыру, иҗади биремнәр әзерләү, мөстәкыйль эшләү өчен күнегүләр системасын булдыру ярдәм итә.Үзем фәнни - популяр журналлардагы язмалар белән даими танышып баррырга тырышам.

Санап үткәннәрдән чыгып, 12 нче кызлар гимназиясендә үз һөнәренә гашыйк, укучыны шәхес буларак кабул иткән, компетентлы педагоглар эшли, дип нәтиҗә ясыйсым килә.